| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>СТАРОКАКЕРЛИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ИСКЕ КӘКЕРЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

Иске Какерли

2020 20 мае № 62/3

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Иске Кәкерле
авыл җирлеге Советының «Физик
затлар милкенә салым турында»гы
карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып билгеләү тәртибен куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлеге Уставы нигезендә Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлеге Советының 2019 елның 15 ноябрендәге 56/5 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.:

**2 пунктта:**

**1 пунктчага түбәндәге** эчтәлекле **абзацлар** өстәргә:

«составына бер генә торак йорт керә торган Бердәм күчемсез комплекслар исемлеге;

мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яки корылмалары.»;

**3 пунктның дүртенче абзацын** төшереп калдырырга.

2. Иске Кәкерле авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында әлеге карарны халыкка игълан итәргә һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, ләкин ул басылып чыккан көннән бер айдан да иртәрәк түгел.

Иске Кәкерле авыл җирлеге
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы: Н.Л.Исхаков